## 5 нче сыйныф

## Татар әдәбиятыннан тест

## Татар халык әкияте «Ак байтал»

## I вариант

**1. «Байтал» сүзе нәрсәне аңлата?**

а) карт бия;

ә) картайган ат;

б) айгыр.

**2. «Ак байтал» әкияте ничек башлана?**

а) борын-борын заманда булган, ди, бер урта хәлле крестьян;

ә) борын заманда бер карчыкның өч кызы булган, ди;

б) берәүнең бер кызы белән бер улы булган, ди.

**3. «Ак байтал» әкиятенең төп герое кем?**

а) карт;

ә) Тиле;

б) олы малайлар.

**4. Игеннәрне ни сәбәпле саклыйлар?**

а) төн үтүгә, бер кибән юкка чыкканга күрә;

ә) кеше тимәсен, дип;

б) малайларга эш булсын, дип.

**5. Агайның ничә малае була?**

а) берәү;

ә) икәү;

б) өчәү.

**6. Тиле гаиләдә ничәнче бала була?**

а) беренче;

ә) икенче;

б) өченче.

**7. Ак байталлар нинди була?**

а) өчесе дә тау кадәр — зурлар, өчесе дә ап-ак — яңа яуган кар шикелле;

ә) бик матурлар, ак төстә;

б) барысы да ак төстә, тик берсе кечкенә.

**8. Ак байталны агай нишләтмәкче була?**

а) суеп ашарга уйлый;

ә) сукага җигә;

б) патшага илтеп сатарга карар кыла.

**9. Тиленең абыйлары патша яшәгән шәһәргә ничек бара?**

а) пар алаша җигеп;

ә) Ак байталга атланып;

б) җәяүләп.

**10. Ак байталны карт күпмегә сата?**

а) бер мең алтынга;

ә) өч мең алтынга;

б) бер капчык алтынга.

**Ачкыч**

1. **А**
2. **А**
3. **Ә**
4. **А**
5. **Б**
6. **Б**
7. **А**
8. **Б**
9. **А**
10. **Ә**

# Бәяләү

## 9-10 балл – “5”ле
## 7-8 балл – “4”ле
## 5-6 балл – “3”ле

**II вариант**

**1.Патша шәһәренә барганда, Тиле нәрсә таба?**

а) акча янчыгы;

ә) Сәмруг кош каурые;

б) китап.

**2.Сәмруг кош каурыен әкият герое ничек файдалана?**

а) патшага бүләк итә;

ә) Ак байталны чистарту өчен куллана;

б) кадерләп саклый.

**3. Сәмруг кош — нинди кош ул?**

а) сайрый торган кош;

ә) күчмә кош;

б) бик эре һәм көчле, гадәттән тыш тиз оча торган кош.

**4. Патша Тилегә нинди әмерләр бирә?**

а) Сәмруг кошны тотып китерергә;

ә ) өенә кайтып китәргә;

б) Ак байталны далага җибәрергә.

**5. Патша Тилегә өченче мәртәбә нинди эш куша?**

а) Сәмруг кошны тотып китерергә;

ә ) Җен патшасының кызын алып кайтырга;

б) кырык баш җен байталы тотып китерергә.

**6. Дәреслектә бирелгән иллюстрация кайсы рәссамныкы?**

а) Харис Якуповныкы;

ә) Раушания Якупованыкы;

б) Фәридә Ризаеваныкы.

**7. Әкияттә бирелгән патшаның исеме ничек?**

а) Александр;

ә) Микулай;

б) Владимир.

**8. Патша, Тиле ул кушканга каршы килгәч, нәрсә ди?**

а) Син әле шулаймыни? Хәзер солдат чакыртып аттырам үзеңне!

ә) Син әле шулаймыни? Хәзер төрмәгә яптырам үзеңне!

б) Син әле шулаймыни? Хәзер этләрдән талатам үзеңне.

**9. Патшаның соңгы әмере нинди?**

а) син Сәмруг кошны тотып китер;

ә) җен патшасының кызын алып кайт;

б) шулай-шулай, син теге җен бияләрен савып чык, сөтен казанга салып кайнат та шуңа өч тапкыр чумып чык — минем әмерем шул.

**10. Тиле патшаны ничек җиңгән?**

а) Ак байтал киңәшләрен тыңлаган;

ә) бик көчле булган;

б) абыйларын ярдәмгә чакырган.

## Ачкыч

1. Ә
2. Ә
3. Б
4. А
5. Ә
6. Б
7. Ә
8. А
9. Б
10. А

# Бәяләү

## 9-10 балл – “5”ле

## 7-8 балл – “4”ле

## 5-6 балл – “3”ле